РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

28.05.2019

№ 540-па

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы җирлегендә
«Саба» Индустриаль паркы булдыру
турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында, икътисадның сәнәгать тармаклары урнашкан җирләрен үстерү, яна төр продукцияләр җитештерү, аеруча прогрессив технологияләр һәм җитештерү төрләре кертү максатыннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирлегендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Саба» индустриаль паркын төзергә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының “Саба” индустриаль паркы турындагы нигезләмәсен расларга.

3. Индустриаль парк белән ышанычлы идарә итү вәкаләтләрен “Саба” индустриаль парк Идарә компаниясе” Акционерлык җәмгыятенә тапшырырга.

4. «Саба» индустриаль паркының резидентларны сайлап алу буенча конкурс Комиссиясен түбәндәге составта билгеләргә:

– Ишниязов Марат Рашат улы – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

– Котдусов Илнур Илдус улы - Башкарма комитет җитәкчесенең инвестицион һәм территориаль үсеш буенча урынбасары-инвестицион үсеш бүлеге башлыгы;

– Галиуллин Алим Мәгьсүм улы - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе ;

– Хуҗин Илшат Тәлгать улы – “Саба” индустриаль парк Идарә компаниясе “АҖ нең генераль директоры;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Совет Аппаратының юридик бүлек начальнигы Миникаев Альберт Илдар улы.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының “Саба” индустриаль паркы территориясендә резидентлар тарафыннан алып барылган инвестиция һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге турында килешүне расларга;

6. «Саба» индустриаль паркының Күзәтчелек советын түбәндәге составта билгеләргә:

– Ишниязов Марат Рашат улы – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

– Котдусов Илнур Илдус улы - Башкарма комитет җитәкчесенең инвестицион һәм территориаль үсеш буенча урынбасары-инвестицион үсеш бүлеге башлыгы;

– Галиуллин Алим Мәгъсүм улы - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе ;

– Хуҗин Илшат Тәлгать улы – “Саба” индустриаль парк Идарә компаниясе “АҖ нен генераль директоры»;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Совет Аппаратының юридик бүлек начальнигы Миникаев Альберт Илдар улы.

7. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 нче елның 1 нче октябрендәге 1463-п номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы “Саба” сәнәгать мәйданчыгының Күзәтчелек советы составын һәм нигезләмәсеи раслау турында”гы карарын үз кочен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының

______________________

карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының
“Саба” индустриаль паркы турында
Нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР.

1.1. Әлеге Нигезләмә, индустриаль паркларга керүче объектларны булдыру аркылы, Татарстан Республикасының Саба муниципаль районында уңай инвестицион һәм инновацион климатны хокукый, методик, оештыру, икътисадый, финанс һәм социаль яктан тәэмин итү максатында эшләнде.

1.2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының “Саба” индустриаль паркы, эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен уңай шартлар тудырылган һәм уртак чиге булган җир кишәрлекләрендә территориаль аерымланган комплекс булып тора.

## 2. ӘЛЕГЕ НИГЕЗЛӘМӘДӘ КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН ТӨП ТӨШЕНЧӘЛӘР.

2.1. Индустриаль парк – бердәм инфраструктураны куллануга юнәлтелгән, төрле производстволарны (үзәкләрне, бүлекчәләрне һ.б.) урнаштыру һәм аларның нормаль эшләве өчен кирәк булган биналарны һәм корылмаларны кертеп, барлык инженерлык, транспорт, эшлекле һәм социаль инфраструктура элементлары булган территориянең тözеклэндерелгән өлеше.

2.2. Идарә компаниясе-индустриаль парк төзү, аның белән идарә итү, шулай ук индустриаль парк территориясендә урнашкан инфраструктура объектларын һәм башка объектларны эксплуатацияләү белән бәйле эшләрне башкаручы оешма.

2.3. Индустриаль парк резиденты- индустриаль парк территориясендә сәнәгать-җитештерү, техник-гамәлгә кертү эшчәнлеген алып бару буенча,шушы нигезләмәдәге шартлар һәм тәртип белән билгеләнгән, Идарә компаниясе белән килешү төзегән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының индустриаль парк урнашкан территориясендә теркәлгән хуҗалык субъекты.

2.4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы администрациясе – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты.

2.5. Сәнәгать-җитештерү эшчәнлеге – чимал һәм материалларны эшкәртү, товарлар җитештерү, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлек.

2.6. Техник-гамәлгә кертү эшчәнлеге – алдынгы техник һәм технологик карарларны булдыру һәм гамәлгә кертү, фәнни-техник продукция эшләү, фәнни сыйдырышлы товарлар һәм хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру, аларны сәнәгать кулланышына җиткерү буенча эшчәнлек.

## 3. ИНДУСТРИАЛЬ ПАРК ТӨЗҮНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ.

3.1. Индустриаль парк инновацион өлкә, сәнәгать, логистика һәм шуңа бәйле сервис объектларын урнаштыруга әзерләнгән мәйданчыкларда инвесторларның ихтыяҗын нәтиҗәле канәгатьләндерү,халыкның яшәү шартларын яхшырту, инвестицион һәм инновацион климатны яхшырту аркылы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының үсеш дәрәҗәсендә аерымлыкны тигезләү, эшкә сәләтле халыкның мәшгульлеген тәэмин итү һәм конкурентлыкка сәләтле сәнәгать җитештерүләренең индустриаль парклар һәм шуңа бәйле сервислар базасында эш җәелдерү өчен шартлар тудыру максатларында булдырылды.

3.2. Индустриаль паркларны булдырганда төп бурычлар булып түбәндәгеләр тора:

- Саба муниципаль районының социаль-икътисади үсешенең комплекслыгын, баланслыгын һәм пропорциональлеген тәэмин итү;
- Индустриаль парк инфраструктурасын булдыру һәм төзекләндерүнең бөтен чоры дәвамында инвестицион эшчәнлек шартларының тотрыклылыгын тәэмин итү;
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында, икътисадның (сәнәгать) тармаклары урнашкан җирләрен үстерү , яңа төр продукцияләр җитештерү, аеруча прогрессив технологияләр һәм җитештерү төрләре кертү.

3.3. Паркның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- Җитештерүче, административ һәм лаборатор мәйданнардагы ихтыяҗларны канәгатьләндерүне, шулай ук яңа технологияләр һәм продуктларны эшләү һәм гамәлгә кертү өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итә торган алга киткән инфраструктура булдыру;
- Яңа сәнәгать җитештерүләрен оештыру һәм гамәлдәге сәнәгать җитештерүләрен камилләштерү;
- Уйлап табу һәм рационализаторлык эшчәнлеген стимуллаштыру һәм аның нәтиҗәләрен гамәлгә кертү;
- Районның социаль-икътисади үсешен:

1) Эчке һәм чит ил инвестицияләрен җәлеп итү;
2) Заманча һәм инновацион технологияләр кертү;
3) Кече һәм урта предприятиеләр секторын үстерү;
4) Заманча идарә итү методларын куллану;
5) Ачык милекне нәтиҗәлерәк куллану;
6) Эш урыннары булдыру чаралары ярдәмендә тизләтү.

## 4. ПАРК ТЕРРИТОРИЯСЕ.

4.1. Парк территориясе Саба шәһәр җирлеге Байлар Сабасы ш. т. п.ның торак пункт чигендә: Байлар Сабасы ш.т.п., Заводская ур., Заводская тыкрыгы адресы буенча урнашкан.

4.2. Саба муниципаль районы башкарма комитеты, Саба муниципаль районы мөлкәтендә булган милекне, паркның Идарә компаниясе идарәсенә тапшыра.

## 5. ПАРК ИДАРӘСЕ.

5.1. Парк белән идарә итү Идарә компаниясенә йөкләнә.

5.2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Саба» Паркы Идарә Компаниясе – Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән ,ышанычлы

житәкче буларак сайланган,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Саба» паркы белән идарә итүче юридик зат.

5.3. Идарә компаниясенең максатлары һәм бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- Парк резидентлары эшчәнлеген координацияләү;
- Парк эшчәнлеген тәэмин итү;
- Парк резидентларына кирәкле ярдәм күрсәтү.

5.4. Идарә компаниясенең функцияләре:

А) Индустриаль парк белән турыдан-туры идарә итә һәм аның эшчәнлеген тәэмин итә;

Б) Үз һәм җәлеп ителгән акчаларны кулланган очракта, индустриаль парк эшчәнлеген тәэмин итә торган инфраструктура объектларын проектлау һәм төзү буенча, индустриаль парк территориясен планлаштыру документларын эшләү буенча заказчы һәм инвесторның вазыйфаларын башкара һәм хокукларын гамәлгә ашыра ;

В) Индустриаль парк булдыру һәм аның эшчәнлеге белән бәйле эшләрне финанс ягыннан тәэмин итә;

Г) Милек ала,мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокуклар булдыра, кирәкле инвестицион ресурсларны,шул исәптән индустриаль парк төзү һәм аның инфраструктурасы эшчәнлеген тәэмин итү өчен инвестицияләр белән беррәттән, башка финанс һәм матди чараларны җәлеп итә.

Д) Индустриаль парк эшчәнлеген тәэмин итә торган инфраструктура объектларын төзүне, оештыруны яки (һәм) эксплуатацияләүне (хезмәт күрсәтүне) гамәлгә ашыра;

Е) Индустриаль парк территориясе белән кызыксынган хуҗалык субъектларын (резидентларны) җәлеп итү өчен кирәкле чараларны гамәлгә ашыра;

Ж) Индустриаль парк резиденты белән сәнәгать-җитештерү һәм (яки) техник-гамәлгә кертү эшчәнлеген алып бару турында килешү төзи, анда җир кишәрлегеннән һәм индустриаль парк инфраструктурасыннан файдалану, инженер-техник тәэмин ителеш мәсьәләләрен карап чыга;

З) Проект документларына, матди-техник тәэминатка, персоналны яллауга кирәкле экспертизаларны узуда парк резидентларына ярдәм күрсәтә;

И) Үзара хезмәттәшлек турында килешүдә каралган башка функцияләрне башкара;

К) Парк чикләрен үзгәртү турында тәкъдимнәр кертә;

Л)Парк эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапларга анализ ясый;

М) Парк территориясендә арендага бирелгән җир участокларының булмавы турындагы мәгълүматны басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгара;

Н)Парк резидентлары реестрын алып бара;

О) Энергоресурсларга тоташтыру, күмәк кулланылыштагы территорияләрне санитар чистарту, парк территориясен саклау, транспорт, мәгълүмати һәм башка хезмәтләр күрсәтә;

П) Эшчәнлек алып бару һәм килешүләр төзү өчен парк резидентларына буш мәйданнар һәм (яки) биналар тәкъдим итә ;

Р) Саба районы Башкарма комитетының вәкаләтле органына – Парк резиденты тарафыннан парк территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешүнең үтәлеше буенча һәм үз эшчәнлеге буенча квартал саен хисап бирә.

## 6. ПАРКНЫ ФИНАНСЛАУ.

6.1. Паркны финанслау һәм үстерү, шул исәптән, һәр резидентның җитештерү, транспорт һәм башка инфраструктурасыи финанслау һәм үстерү, парк резиденты һәм башка чыганаклар хисабына гамәлгә ашырыла.

## 7. ПАРКНЫҢ КҮЗӘТЧЕЛЕК СОВЕТЫ.

7.1. Парк территориясендә инвестицион проектларны тормышка ашыруныц барышын, муниципаль бюджет акчалары бүленеп бирүне контрольдә тоту, паркныц Идарә компаниясенә дәүләт ярдәме күрсәтүнец максатка ярашлылыгы турында нәтиҗәләр әзерләү, гомуми Попечительләр функцияләрен тормышка ашыру, парк территориясендә эшчәнлек алып бару өчен гаризаларны эксперт бәяләү максатында, паркныц Күзәтчелек советы булдырыла.

7.2.Күзәтчелек Советы составы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының карары белән раслана.

7.3. Паркның Күзәтчелек советы, контрольлек функцияләрен үтәү максаты белән:

– Кварталга кимендә 1 тапкыр Күзәтү советы утырышларын үткәрә;

– Парк Идарә компаниясе һәм парк резидентлары эшчәнлеге турында хисап сорый;

– Парк үсеше өчен өстәмә юнәлешләр эшли;

– Идарә компаниясенец алдагы чорларга планнарын раслый.

## 8. ПАРК ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕК.

8.1. Резидент- Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән ,парк территориясендә аныц белән эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару турында килешү төзелгән, эшмәкәрлек субъекты.

8.2. Парк резидентлары, Россия Федерациясе законнары һәм мәйданчык территориясендә эшчәнлек алып бару турында төзелгән килешү нигезендә, Парк территориясендә эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге алып бара.

8.3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты Парк резидентларыныц тотрыклылыгын гарантияли һәм Парк гамәлдә булу вакыты дәвамында аларның эшчәнлеге шартларын начарайта алмый.

## 9. ПАРК ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ЭШЧӘНЛЕК АЛЫП БАРУ ТУРЫНДА КИЛЕШҮ.

9.1. Парк резиденты Парк территориясендә эшчәнлек алып бару турында Идарә компаниясе белән килешү төзи.

9.2. Парк территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешү буенча, Парк резиденты ,килешүнец гамәлдә булу срогы дәвамында,Парк территориясендә эшчәнлек алып барырга, шул исәптән килешүдә каралган күләмдә һәм вакыт эчендә инвестицияләр кертергә , ә Идарә компаниясе парк резидентына кирәкле ярдәмне күрсәтергә вәгъдә бирә; шулай ук,Идарә компаниясе,резидент үз йөкләмәләрен тулы күләмдә үтәгәннән соц,ягъни бизнес-планда күрсәтелгән түбәндәге:

1) эш урыннары саны;

2) кертелгән инвестицияләр күләме;

3) салым түләүләре буенча күрсәткечләргә ирешкәннән соң, резидентка, бизнес-планын гамәлгә ашыру өчен бирелгән җир кишәрлеген сатып алу мөмкинлеген бирә.

9.3. Парк резиденты Парк территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү буенча үз хокукларын һәм бурычларын башка затка тапшырырга хокуклы түгел.

## 10. ПАРК ТЕРРИТӨРИЯСЕНДӘ ЭШЧӘНЛЕК АЛЫП БАРУ ТУРЫНДА КИЛЕШҮ ТӨЗҮ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ ДӨКУМЕНТЛАР.

10.1. Парк резиденты статусын алырга ниятләгән зат, Идарә компаниясенә, гамәлгә кую һәм башка документларны кушып, парк территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү төзү өчен гариза тапшыра.Ул гариза түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

1) Мөрәҗәгать итүченен Парк тибына туры килә торган фаразланган эшчәнлеге турында белешмәләр;

2) Мөрәҗәгать итүченең фаразлана торган эшчәнлеге өчен кирәкле булган җир кишәрлеге яисә урын мәйданы турында белешмәләр;

3) Парк территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү төзелгәннән соң, ел дәвамында күз алдында тотылган инвестицияләр күләме турында белешмәләр.

10.2. 10.1 пунктында күрсәтелгән документлар, идарә компаниясе тарафыннан, тасвирлама буенча кабул ителә. Документларны кабул итү датасы турындагы тасвирлама күчермәсен вәкаләтле орган гариза бирүчегә җибәрә (тапшыра).

10.3. Компания, документларны алганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, 10.1. пунктында күрсәтелгән берәр карарны кабул итә һәм гариза бирүчегә җибәрә:

1) Эксперт бәяләве өчен парк территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы гаризаны Компаниягә кертү хакында;

2) Мөрәҗәгать итүчегә документларны кире кайтару турында.

Гариза бирүчегә документларны кире кайтару түбәндәге очракта рөхсәт ителә:

1) Зат 10.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаса;

2) Парк территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү төзү өчен язылган гаризада, күрсәтелгән шартларга җавап бирә торган Ирекле җир кишәрлеге һәм (яки) урын булмаса;

3) Гариза бирүче эшчәнлегенең парк төзү максатларына туры килмәве.

10.4. Парк Конкурс Комиссиясе гаризаны эксперт бәяләү нәтиҗәләре нигезендә Конкурс Комиссиясенең утырыш протоколы бирелә.

## 11. ПАРК ТЕРРИТОРИСЕНДӘ ЭШЧӘНЛЕК АЛЫП БАРУ ТУРЫНДАГЫ КИЛЕШҮНЕ ТӨЗҮ ҺӘМ ӨЗҮ ТӘРТИБЕ.

11.1. Паркның Идарә компаниясе,парк территориясендә эшчәнлек алып бару өчен төзелгән килешүнең максатка ярашлылыгы турында Карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, парк территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү әзерли һәм гариза бирүче белән килешү төзи.

11.2. Парк территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешү яклар кул куйган көннән үз көченә керә.

11.3. Парк территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешү, парк резиденты тарафыннан парк территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешүнең шартлары бозылган очракта өзелергә мөмкин.

11.4. Парк резиденты тарафыннан парк территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешү шартларын җитди бозу булып түбәндәгеләр тора:

1) Парк территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешүдә каралган күләмдә һәм срокларда инвестицияләрне гамәлгә ашырмау;

2 Парк территориясендә эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару турындагы килешүдә каралмаган эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару.;

3) Идарә компаниясе таләбе буенча парк резиденты эшчәнлеге турында кирәкле мәгълүмат бирмәү;

11.5. Парк территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү өзелгән очракта, зат парк резиденты статусын югалта.

11.16. Парк резиденты статусын югалткан зат Парк территориясендә гомуми нигезләрдә эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бара.

## 12. ПАРК ТЕРРИТОРИСЕНДӘГЕ БӘХӘСЛӘРНЕ ХӘЛ ИТҮ.

12.1. Парк эшчәнлеген барлыкка китерү яки аны туктатуга бәйле бәхәсләр, парк резидентлары һәм Идарә компаниясе тарафыннан парк территориясендә тиешле эшчәнлек алып бару шартларын бозуга бәйле бәхәсләр, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җайга салына торган мөнәсәбәтләрдәге башка бәхәсләр Россия Федерациясе законнары нигезендә хәл ителә.

## 13. ПАРК ЭШЧӘНЛЕГЕН ТУКТАТУ.

13.1. Паркныц эшчәнлеген туктату, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан, парк эшчәнлеген туктату турындагы карар буенча рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
территориясенең «Саба» индустриаль паркында
инвестицион һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару турында
КИЛЕШҮ

« ___» __________ 20__ г. № ________

"Саба" АҖ "Индустриаль паркы идарә компаниясе ___________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме) исеменнән,
гамәлдәге _______________________________________, (актның исеме, номеры, датасы) нигезендә,бер яктан, алга таба «Компания " дип аталачак, һәм_______________________________________________ (оешманыц исеме) Резидент _____________________________, (вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасыныц исеме) исеменнән, гамәлдәге ________________________________(актныц исеме, номеры, датасы)нигезендә, икенче яктан, "Саба муниципаль районы территориясендә "Саба индустриаль паркы" акционерлык җәмгыяте турында" гы нигезләмә нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

Килешү предметы.

1.1. Әлеге килешүнец предметы булып, әлеге килешүгә кушымта итеп бирелгән бизнес-план нигезендә, «Саба» индустриаль паркы территориясендә инвестицион һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып бару тора: ____________________________________________________________________________________________________________________________________________________. (Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында инвестицион һәм эшкуарлык эшчәнлеге торе)

2. Килешү төзүчеләрнец хокуклары һәм бурычлары.

2.1. Компания:

2.1.1. Резидентның тиешле гаризасын алгач, ___эш көненнән дә соцга калмыйча, инвестицион һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен ,"Саба" индустриаль паркы чикләрендә урнашкан мәйданнарны арендалау (субаренда) шартнамәсе төзергә тиеш.

Мәйданнарны арендалау срогы әлеге килешүнең гамәлдә булу срогыннан артмаска тиеш.

2.1.2. Әлеге килешүгә кул куелганнан соц өч көн дәвамында «Саба» индустриаль паркы резидентлары реестрына резидентны теркәү турында язма кертергә тиеш.

2.1.3. Резидентка "Саба" индустриаль паркы резиденты буларак теркәлүне раслаучы билгеләнгән үрнәктәге таныклык бирергә тиеш.

2.1.4. Инженер-техник челтәрләргә тоташуныц техник шартларын алу, Россия Федерациясе законнары нигезендә объектны төзүгә, файдалануга тапшыруга рөхсәт алу һәм аларны «Саба» индустриаль паркы чикләрендә төзүне яки реконструкцияләүне башкаручы резидентка, аның гаризасын алу датасыннан __ көннән соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

2.1.5. Резидентка, аның гаризасын алу датасыннан __ көннән соңга калмыйча, " Саба» индустриаль паркы резидентлары реестрыннан күчермә бирергә тиеш.

2.1.6. Резидент тарафыннан әлеге килешүнең үтәлешен контрольдә тотарга тиеш.

2.1.7. Компаниянец Россия Федерациясе законнары буенча каралган башка бурычлары бар.

2.2. Компаниянең:

2.2.1. «Саба»индустриаль паркы идарәсе функцияләрен үтәү буенча, үз вәкаләтләре кысаларында, Резиденттан кирәкле мәгълүмат һәм документлар алырга хокукы бар.

2.2.2. Компания Россия Федерациясе законнары буенча каралган башка хокукларга ия.
2.3. Резидент:
2.3.1. «Саба» индустриаль паркы территориясендә бары тик килешүдә каралган инвестицион һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген генә алып барырга бурычлы.
Бизнес-планда каралган чараларны үтәү барышында:
- Түбәндәге этаплар буенча инвестицияләр, шул исәптән капиталь кертемнәр кертергә:________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
___________________. (инвестицияләрнең вакыты һәм күләме, шул исәптән капиталь кертемнәр, сумнарда)
- Парк территориясендә________кадәр кимендә_______ эш урыннары булдырырга;
- Бюджетның барлык өлкәләрендә еллап салым түләүләрен гамәлгә ашырырга бурычлы.
2.3.3. Әлеге килешү төзелгәннән соң, ___ эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән- «Саба»индустриаль паркы чикләрендә урнашкан мәйданчыкны арендага бирү турындагы гаризаны-компаниягә җибәрергә бурычлы.
2.3.4. Проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алгач, ____көненнән дә соңга калмыйча,Компаниягә, Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән ,төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризаны җибәрергә бурычлы.
2.3.5. Резидент Россия Федерациясе законнарында каралган башка вазыйфаларга ия.

Резидент:
2.4.1. «Саба» индустриаль паркы резидентлары реестрыннан язма сорау нигезендә өземтә алу;
2.4.2. «Саба»индустриаль паркы резиденты буларак теркәлүне раслаучы билгеләнгән үрнәктәге таныклык алу;
2.4.3. Россия Федерациясе законнары нигезендә, «Саба» индустриаль паркы территориясендә урнашкан күчемле һәм күчемсез милек белән үзе теләгәнчә эш итү хокукларына ия;
2.4.4. Резидент Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокукларга ия.

3. Килешүнең гамәлдә булу срогы.

3.1. Әлеге Килешү _______кадәр төзелә һәм килешү төзүчеләр кул куйган датадан үз көченә керә.
3.2. Әлеге килешүнең гамәлдә булу срогы килешү төзүчеләрнең үзара ризалыгы буенча чикләнмәгән вакытка озайтылырга мөмкин.

4. Килешүне үзгәртү һәм өзү шартлары.

4.1. Әлеге килешү, килешүгә кертелә торган сөйләшүләр тәртибендә үзгәртелергә, әлеге килешүгә өстәмә килешүләр кертү белән Рәсмиләштерелергә Мөмкин.
4.2. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы :
4.2.1. Әлеге килешүнең төзелү срогы тәмамланганнан соң;
4.2.2. Әлеге килешү өзелгән очракта;
4.2.3. Аренда килешүе җир кишәрлеген сатып алу белән бәйле рәвештә өзелә торган очраклардан тыш, әлеге Килешүдә каралган җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе туктатылган очракта;
4.2.4. Резидент "Саба" индустриаль паркы резиденты статусыннан мәхрүм ителгән очракта;

4.2.5. «Саба»индустриаль паркы эшчәнлеге вакытыннан алда тәмамланган очракта туктатыла.
4.3. Әлеге Килешү яклар килешүе белән өзелергә мөмкин.
4.4. Әлеге килешү якларның берсе таләбе буенча, икенче як тарафыннан, Килешүдәге шартлар сизелерлек бозылган очракта, шулай ук Саба муниципаль районы территориясендә «Саба» индустриаль паркын төзү турындагы карарда каралган башка нигезләр буенча, суд тарафыннан өзелергә мөмкин.
4.5. Әлеге килешү буенча, Килешү төзүчеләр тарафыннан үз өсләренә алынган йөкләмәләрне үтәү барышында, түбәндәгеләр җитди бозу булып тора:
4.5.1. "Саба" индустриаль паркы территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешүдә каралган күләмдә һәм срокта инвестицияләрне гамәлгә ашырмау;
4.5.2. "Саба" индустриаль паркы территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешүдә каралмаган эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
4.5.3. Саба " индустриаль паркы Идарә компаниясе таләбе буенча «Саба» индустриаль паркы резиденты эшчәнлеге турында кирәкле мәгълүмат бирмәү;

## 5. Килешү төзүчеләрнең җаваплылыгы.

5.1. Әлеге килешүдәге йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, Килешү төзүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тота.
5.2. Резидент әлеге килешүнең 4.5 пунктында күрсәтелгән шартларны җитди бозу сәбәпле,әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылса, “ Саба” индустриаль паркы резиденты статусын югалткан зат,(”Саба” индустриаль паркы резиденты статусын югалткан датага кадәр гамәлгә ашырылган инвестиция күләмен исәикә алмыйча), әлеге килешүнең 2.3.2 пунктында каралган инвестицияләр (капитал кертемнәр) суммасының 5% ы күләмендә неустойка түләргә тиеш.
5.3. Килешү төзүчеләр, көтелмәгән һәм хәл итеп булмый торган хәлләр килеп туган очракта, әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәү җаваплылыгыннан азат ителәләр.
5.4. Көтелмәгән һәм хәл итеп булмый торган хәлләр булып,Килешү төзүчеләрнең ихтыярына һәм теләгенә бәйле булмаган, алар алдан күрә һәм булдырмый кала алмаган теләсә кайсы гадәттән тыш вакыйгалар тора. Мондый хәлләргә түбәндәгеләр керә: хәрби гамәлләр, кораллы конфликтлар, иҗтимагый тәртипсезлекләр, террор актлары, атом-төш, химик яки биологик зарарланулар, эпидемияләр, табигый бәла-казалар, техноген һәлакәтләр, дәүләт хакимияте органнарының актлары һәм гамәлләре, әлеге килешү буенча Килешү төзүчеләрнең ,башка затларның гамәлләре аркасында, йөкләмәләрне вакытында үти алмаулары (Мондый хәлләрнең әлеге килешү буенча Килешү төзүчеләрнең берсе тарафыннан йөкләмәләрне турыдан-туры бозуы аркасында килеп чыгу очракларыннан тыш).
5.5. Көтелмәгән һәм хәл итеп булмый торган хәлләр килеп чыккан очракта, бер як, өч эш көненнән дә соңга калмыйча, икенче якка аларның һөҗүмнәре турында хәбәр итәргә тиеш. Хәбәрнамә үз эченә бу хәлләрнең характеры турында мәгълүматны, шулай ук бу хәлләрнең булуын раслаучы документларны алырга тиеш.
5.6. Килешү төзүчеләр, көтелмәгән һәм хәл итеп булмый торган хәлләр килеп чыгуы турында хәбәрнамә алган мизгелдән алып 30 эш көне эчендә, көтелмәгән һәм хәл итеп булмый торган хәлләр йогынтысын киметү өчен,хезмәттәшлекнең иң нәтиҗәле тәртибен, шулай ук әлеге килешү шартларын үтәүнең иң кулай ысулларын билгеләргә тиеш.
5.7. Көтелмәгән һәм хәл итеп булмый торган хәлләр, әлеге килешү буенча килешү төзүчеләрнең йөкләмәләренең барлык яки мөһим өлешенең үтәлү вакытын сизелерлек тоткарласа яки бозса, икенче як тарафыннан көтелмәгән һәм хәл итеп булмый торган хәлләр килеп чыгуы турында хәбәр алынганнан соң 180 көн эчендә, килешү төзүчеләрнең һәрберсе, икенче якка, әлеге килешүне өзү турында, әлеге килешү

гамәлдә булу туктатылганга кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, хәбәр җибәргә хокуклы.

6. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе.

6.1. «Саба» индустриаль паркын булдыру яки аның гамәлдә булуын туктату, «Саба» индустриаль паркы Идарә компаниясе һәм резидентларның «Саба» индустриаль паркы территориясендә тиешле эшчәнлек алып бару шартларын бозу белән бәйле бәхәсләр, шулай ук башка бәхәсләр Россия Федерациясе законнары нигезендә хәл ителә.

7. Йомгаклау нигезләмәләре.

7.1. Резидент әлеге килешү буенча башка затка үз хокукларын һәм бурычларын тапшырырга хокуклы түгел.

7.2. Резидент үз статусын югалткан һәм Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән нигезләр буенча килешү гамәлдә булмаган очракта, резидент тарафыннан төзелгән «Саба» индустриаль паркы чикләрендәге мәйданчыкны арендалау шартнамәсенең гамәлдә булуы туктатыла.

. 7.3. Әлеге килешү ике нөсхәдә төзелде, Килешү төзүчеләрнең һәркайсы өчен бер нөсхәдә һәм бер үк юридик көчкә ия .

7.4. Әлеге килешүгә -

7.4.1. Бизнес-план кушымта итеп бирелә һәм аның аерылгысыз өлеше булып тора.

Килешү төзүчеләрнең реквизитлары һәм имзалары:

__________________-(____________)    ________________________(__________)